Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Елховой авыл Советы
КАРАРЫ

30 октябрь 2020 ел № 7

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Елховой авыл җирлегенең пенсиягә чыгу
уңаеннан муниципаль хезмәткәр вазифаларын
башкаручыга тиешле еллар эшләгән өчен
бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү
тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлеге Уставы нигезендә

Елховой авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәр вазифаларын башкаручыга тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Елховой авылы, Совет урамы, 67 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Елховой авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Елховой авылы җирлеге Башлыгы А.А. Хәсәншин

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл Советының 2020 елның 30 октябрендәге 7 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәр вазифаларын башкаручыга тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында
Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәр вазифаларын башкаручыга тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

2. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәре вазифаларын даими рәвештә башкаручыга тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмен билгели.

3. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк җирле үзидарә органы тарафыннан түләнә, муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә эштән китәр алдыннан башкарылучы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Акчалата бүләкләү хезмәт кенәгәсенә тамга салып бер мәртәбә түләнә. Пенсиягә чыккач һәм муниципаль вазифаны биләүче затның вәкаләтләре беткәннән соң муниципаль хезмәткәр хезмәт вазифаларын башкаруга кабаттан кайтарылса, тиешле еллар эшләгән өчен акчалата бүләкләү кабат түләнми.

5. Муниципаль вазифаны даими нигездә биләүче затка, муниципаль вазифадан пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә эштән азат ителгәндә, муниципаль вазифада яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажы 10 елдан артык булганда ун айлык акчалата бүләкләү күләмендә акчалата бүләк түләнә (айлык акчалата бүләкләүгә керә: айлык акчалата бүләк).

Тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр акчалата бүләкләү «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы 16 өлешенең җиденче абзацында, 6 өлешенең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 36 статьясы 6.1 өлеше, 7.1 өлешенең 5-8 пунктлары, 40 статьяның 10,1 өлеше, 73 статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләр буенча вәкаләтләр туктатылган очракта түләнми.

6. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме даими нигездә муниципаль вазифаны биләү стажыннан, дәүләт пенсиясенә чыкканда дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажыннан чыгып билгеләнә.

7. Бер мәртәбә акчалата бүләкләүне түләү турындагы карар, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль вазифа биләүче затның вәкаләтләрен даими нигездә туктату турындагы карар белән бергә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл Советы карары белән раслана.

8. Бер мәртәбә акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органы бер мәртәбә акчалата түләү турында карар кабул ителгән көннән алып 5 календарь көн эчендә Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

- вәкаләтләрне туктату һәм бер мәртәбә акчалата бүләкләү турында карар (карарлар) күчермәсе;

- муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата эчтәлеге турында белешмә;

- муниципаль вазифада, дәүләт һәм муниципаль хезмәттә җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган эш стажы турында белешмә;

- кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәләре;

- җирлек Башкарма комитетының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган форма (кушымта) буенча башкарылган бер тапкыр бүләкләү исәбе;

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлегендә муниципаль вазифаны биләүче затның һәм муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.

9. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авылы Башкарма комитеты җирле үзидарә органы тарафыннан документлар тапшырганнан соң 10 көн эчендә аңа бюджет ассигнованиеләре һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәр итә яисә әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында каралган барлык документлар да тапшырылмаган очракта, мотивацияләнгән нигездә пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү күләмен билгеләүдән баш тарта.

10. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башкара.

11. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү әлеге Нигезләмә нигезендә Әлмәт муниципаль районы Елховой авылы җирлеге бюджеты акчаларыннан хисабыннан башкарыла.

Елховой авылы җирлеге Башлыгы А.А. Хәсәншин

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Елховой авыл җирлегенең пенсиягә чыгу
уңаеннан муниципаль хезмәткәр вазифаларын
башкаручыга тиешле еллар эшләгән өчен
бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү
тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмәгә
кушымта

Тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу уңаеннан бер мәртәбә
бирелә торган акчалата бүләкне
түләү тәртибе һәм күләме

| | |
|---|---|
| Фамилиясе,Исеме,Әтисенең исеме | |
| Туган көне | |
| Вазифасының атамасы | |
| Җирле үзидарә органы исеме | |
| Айлык акчалата керем күләме (сум) | |
| Хезмәт стажы (тулы еллар)) | |
| Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләү өчен айлык бүләкләүнең саны | |
| Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк (сумнарда) | |

Җитәкче А.А. Хәсәншин